Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Масловка авылы 16.01.2025 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
Муниципаль районы Масловка авыл
Җирлеге Башлыгының 2024 елга хисабы
һәм 2025 елга бурычлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5, 5.1 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 7, 7.1 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башлыгы А.И. Егоровның 2024 ел өчен хисабы һәм 2025 елга бурычлар турында игътибарга алырга, эшне канәгатьләнерлек дип танырга.

2.2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары алдына түбәндәге бурычлар куярга:

2.1. 15.11.2024 көнне узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча үзара салым акчаларын гамәлгә ашырырга.

2.2. Авыл мәдәният йорты түбәсенә капиталь ремонт үткәрү.

2.3. Татарстан Республикасы Рәисен, шулай ук район һәм җирле совет депутатларын сайлауларны уздырырга. 3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге, Масловка авылы, Централь урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнән җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Башлыгы А.И.Егоров